**«БИШЛЕ БИЛГЕСЕ КУЯМ»**
**Әлфия Ситдыйкова**
**иҗаты буенча әдәби композиция**
*(түбән сыйныф укучылары өчен)*

*Сәхнә көз аен хәтерләтә, сары яфрак, көзге чәчәкләр белән бизәлгән.*
*Көзге бакчада бишек тирбәлә. Урындыклар урнаштырылган.*
*Талгын гына көй агыла, сәхнәгә укучылар чыга.*

**1нче укучы:**

Алтын көзнең кочагына
Сыендым әле бүген.
Алтын бөртеге үзем дә
Туган ягым, илемнең.

**2нче укучы:**

Кояш кыйпылчыкларымы? –
Йөзләрдә уйный нуры.
Бөтен дөньяга яңгырый,
Нәни йөрәкнең җыры.

**3нче укучы:**

Нур сибелгән йөзләремә,
Күзләрем балкый нурдан.
Әйтерсең лә бөтен дөнья
Тора гел тоташ җырдан.

**4нче укучы:**

Күр син, җиһан, минем күздә
Чагыла бәхет төсе.
Кешелек, Җир, Ватаныбыз
Балалар белән көчле.

*«Алтын көзнең кочагына»*

*Сәхнәгә алып баручы чыга.*

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле балалар. Бик дөрес язган шагыйрә апабыз.

Кешелек, Җир, Ватаныбыз
Балалар белән көчле.

Бу шигырь юлларының авторы шагыйрә Әлфия Ситдыйкова.Бүген китапханәдә зур бәйрәм.

**1 нче укучы:**Ә нинди бәйрәм соң ул?

**Алып баручы:** Бүген шигырьләр сөйләрбез, шигъри уеннар уйнарбыз. Сезнең белән бергә шигъри бәйрәм ясарбыз.

*Талгын гына көй агыла.*

*1нче укучы бишектән курчак ала, шигырь сөйли,2нче укучыга курчакны бирә, шул рәвешле, курчакны кулдан-кулга биреп, шигырьләр сөйлиләр.*

**1нче укучы:**

Кошлар җырлый, җырлый тамчы,
Җырлап гөрләвек ага.
Җырларыма дәрт, ямь өстәп
Дөньяга туды бала.

**2нче укучы:**

Кечкенә дә, төшкенә лә,
Язның тәүге чәчкәсе.
Кулга ала аны назлап
Әткәсе һәм әнкәсе.

**3нче укучы:**

«Бәхетле бул, тәүфыйклы бул,
И күземнең карасы!» –
Диеп, дога укый-укый
Сөя әби-бабасы.

**4нче укучы:**

Җырлый урман, җырлый җиһан,
Җырлар төренгән назга.
Нәни кызчыгым туганга
Күңел тулышты язга!

*«Бәби тугач»*

*4нче укучы курчакны бишеккә сала. Укучылар утыралар.*

**Алып баручы:** Уңганнар, булганнар җыелган монда. Кечкенә сеңелегез дә шигырь тыңлап йокыга китте. Тәмле төшләр сиңа, сабый. Әнә кояш нурларын тагын да көчлерәк сибә башлады.

*Көй дәвам итә.*

**1нче укучы:**

Нәни кояш нурын сибә
Өебезнең түренә.

**2нче укучы:**

Чеңләп көлгән тавышыннан
Иркенәя күңелләр.

**3нче укучы:**

Йомшак куллар иркәләнеп
Сарылганда муенга,

**4нче укучы:**

Бәхет кошы, әйтерсең лә,
Оя кора куенга.

**1нче укучы:**

Сандугач сайрый өздереп,
Балам җырлый үзгәрәк.

**2нче укучы:**

Күңелле бакчабызда яши
Аллы-гөлле күбәләк!

*«Нәни кояш»*

**Алып баручы:** Әлфия Ситдыйкова шигърияттән башка яши алмый, аның тәненең бөтен күзәнәкләре шигырь белән сулый да, уйлый да. Ул төрле жанрда шигырьләр иҗат итә. Хәзер мин сезгә«омонимлы шигырьләр» укырмын, ә сез омонимнарны әйтергә тиеш буласыз.Ә омоним ул, исегезгә төшерәм – ике мәгънә аңлатучы сүзләр. Сез әзерме? Алай булганда киттек!

*Талгын гына көй агыла.*

**Алып баручы:**

Кояш мангач җете **алга,**
Өзелеп төште безнең **алга,**
Тәгәрәде ике **алма,**
Берсен ал син, берсен **алма.**

**2нче укучы:** Бу шигырьдә **АЛГА, АЛМА** сүзе ике мәгнәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Дәвам итәбез.

Нәни кызчык тәүге тапкыр
Басып килә ап-ак **карга.**
Гаҗәпләнеп, шул мизгелдә
Аваз сала кара **карга.**

**3нче укучы:** Бу шигырьдә **КАРГА**сүзе ике мәгнәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Шигырьне укуны дәвам итәм, тыңлагыз.

Бу инешнең ике ярын
Тоташтыра такта **басма.**

Тар басмадан чыккан чакта,
Берүк сак бул, читкә **басма.**

**4 нче укучы:** Бу шигырьдә **БАСМА** сүзе ике мәгнәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Дәвам итәбез.

Ялгыз басып торам ярда,
Бәлки килер көткән яр да.
Җырлап ага көмеш **чишмә,**
Сереңне дип ятка **чишмә.**

**1нче укучы:** Бу шигырьдә **ЧИШМӘ** сүзе ике мәгнәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Булдырдыгыз. Рәхмәт сезгә, балалар. Әлфия апабыз китаплар укырга ярата, кечкенәдән үк шигырьләр яза. Биредә дә китап укырга яратучылар җыелганнар. Ә сез уеннар яратасызмы?

**2-3нче укучылар:** Яратабыз.

**Алып баручы:** Әйдәгез, бергә «Кем ул?» уенын уйныйбыз. Ничек дисезме? Мин сезгә шагыйрә апаның тагын бер шигырен укыйм. Ә шигырьдә кем турында сүз барганны сез әйтергә тиешсез? Игътибарлы булыгыз, уенны башладык.

И матур ул, ягымлы ул,
Иң җылы куллар кемдә?!
Кем яратып, гел иркәләп,
Уята безне көн дә?
Кем чәчләрне тарап үрә,
Кем бәйли оекбашлар?
Безнең өчен иртүк торып
Пешерә тәмле ашлар?
Кайсыгыз белә җавабын,
Кем ул иң изге кеше?!
Шул зирәк балага куям
Иң олы билге – бишле!

*«Кем ул?!»*

*Укучылар җавабы.*

**Алып баручы:** Бик дөрес, балалар. Дәү әни, Әби, Әни җавапларын әйткән балаларның барысына «5»ле билгесе куям. Безнең Дәү әни, Әби, Әниләребез гаилә учагын саклаучылар, тәмле ашлар пешереп, мәктәпкә

озатырга да, йоклаганда бишек җырларын көйләргә дә вакытлары җитә аларның. Балалар, сезнең гаиләдә ничә кеше яши?

*Укучылар җавабы.*

**Алып баручы:** Бик яхшы, кемнәрдер өчәү, дүртәү, хәтта алты кеше дә яшиләр икән. Ә шагыйрә апабыз гаиләсендә ничә кеше яшәвен беләсегез киләме?

**Укучылар бергә:** Беләсебез килә, килә.

**Алып баручы:** Алайса игътибар белән тыңлагыз. Мин сезгә шагыйрә апаның тагын бер «Без ничәү?» шигырен укып китәм:

Әткәй, әнкәй, абый, энем,
Ничә кеше без өйдә?
Сана әле, әйдә, Алсу,
Зурмы безнең гаилә?
Әле безнең песи дә бар,
Исемнәре Мыраужан.
Шулай булгач, безнең өйдә,
Яши икән ничә җан?

*«Без ничәү?»*

*Укучылар җавабы.*

**Алып баручы:** Балалар, әйдәгез бергә саныйбыз.

**Җавап:** 1. Әткәй,
2. Әнкәй,
3. Абый,
4. Энем,
5. песи Мыраужан.

**Алып баручы:** Укучылар, бу уенны да җиңеп чыктыгыз. Ә безнең шигъри бәйрәмебез ахырына якынлашты. Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова иҗатына багышланган әдәби композициядә катнашкан һәркемгә «5»ле билгесе куям.

## Файдаланылган әдәбият

Ситдыйкова, Ә. Омонимлы шигырьләр / Ә. Ситдыйкова // Көмеш кыңгырау. – 2010. – 13 март. – Б. 4.

Ситдыйкова, Ә. Серле дөнья: шигырьләр / Ә. Ситдыйкова. – Казан: Идел-Пресс, 2014. – 28 бит